**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

пр. Ленина, дом 17, с. Актаныш, 423740

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: mail.aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ ________ ПР-167 от 12.08.2025 КАРАР № _____

**Эшчәнлекне вакытлыча туктатып тору турында**

«Аккүз төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе азык-төлек блогына капиталь ремонт ясалуга бәйле рәвештә (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының социаль-иҗтимагый инфраструктура объектларына капиталь ремонт ясау буенча 18.11.2024 № 231-р боерыгы нигезендә) Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Аккүз төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең структур бүлекчәсе «Аккүз балалар бакчасы» эшчәнлеген ремонт эшләре тәмамланганчы туктатып торырга.
2. Эшчәнлеген вакытлыча туктатып тору чорында мәктәпкәчә белем бирү учреждениесендә ата-ана түләвен алмаска.
3. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Д.М.Әнвәровага йөкләргә.
5. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 августыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Җитәкче И.Ш.Бариев